**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении критериев включения (исключения) торговых объектов (территорий) в перечень торговых объектов (территорий), расположенных в пределах территории Республики Татарстан и подлежащих категорированию в интересах их антитеррористической защиты

В соответствии с абзацем четвертым пункта 5 требований к антитеррористической защищенности торговых объектов (территорий), утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 19 октября 2017 года № 1273 «Об утверждении требований к антитеррористической защищенности торговых объектов (территорий) и формы паспорта безопасности торгового объекта (территории)», **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемые критерии включения (исключения) торговых объектов (территорий) в перечень торговых объектов (территорий), расположенных в пределах территории Республики Татарстан и подлежащих категорированию в интересах их антитеррористической защиты.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
15 февраля 2022 года
№ УП-125

Утверждены
Указом Президента
Республики Татарстан

от «15» февраля 2022 года

№ УП-125

**Критерии**
**включения (исключения) торговых объектов (территорий) в перечень торговых объектов (территорий), расположенных в пределах территории Республики Татарстан и подлежащих категорированию в интересах их антитеррористической защиты**

1. Критерием включения торговых объектов (территорий) в перечень торговых объектов (территорий), расположенных в пределах территории Республики Татарстан и подлежащих категорированию в интересах их антитеррористической защиты (далее – Перечень), является соответствие торговых объектов (территорий) одной из категорий торговых объектов (территорий), указанных в пункте 12 требований к антитеррористической защищенности торговых объектов (территорий) (далее – Требования), утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 19 октября 2017 года № 1273 «Об утверждении требований к антитеррористической защищенности торговых объектов (территорий) и формы паспорта безопасности торгового объекта (территории)».

2. Критериями исключения торговых объектов (территорий) из Перечня являются:

отсутствие признаков торгового объекта (территории), указанных в пункте 2 Требований;

несоответствие торговых объектов (территорий) ни одной из категорий торговых объектов (территорий), указанных в пункте 12 Требований;

прекращение деятельности на торговом объекте (территории).

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итү максатларында категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлегенә сәүдә объектларын (территорияләрен) кертү (төшереп калдыру) критерийларын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләр һәм сәүдә объектының (территориясенең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләрнең 5 пункты дүртенче абзацы нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада теркәп бирелә торган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итү максатларында категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлегенә сәүдә объектларын (территорияләрен) кертү (төшереп калдыру) критерийларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 15 февраль
№ ПУ-125

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «15» февралендәге
ПУ-125 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итү максатларында категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлегенә сәүдә объектларын (территорияләрен) кертү (төшереп калдыру) критерийлары**

1. Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан һәм аларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итү максатларында категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлегенә (алга таба – Исемлек) сәүдә объектларын (территорияләрен) кертү (төшереп калдыру) өчен критерий булып сәүдә объектларының (территорияләренең) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләр һәм сәүдә объектының (территориясенең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 1273 номерлы карары белән расланган сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләрнең (алга таба –Таләпләр) 12 пунктында күрсәтелгән сәүдә объектлары (территорияләре) категорияләренең берсенә туры килүе тора.

2. Исемлектән сәүдә объектларын (территорияләрен) төшереп калдыру критерийлары түбәндәгеләр:

Таләпләрнең 2 пунктында күрсәтелгән сәүдә объекты (территориясе) билгеләре булмау;

сәүдә объектларының (территорияләренең) Таләпләрнең 12 пунктында күрсәтелгән сәүдә объектлары (территорияләре) категорияләренең берсенә дә туры килмәве;

сәүдә объекты (территориясе) эшчәнлеген туктату.

---